РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов урам, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.10.2019 № 24

Татарстан Республикасы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2009 елның 28 декабрендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында " карары белән расланган Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 10.09.2009 ел, №02-01-20-19 хаты, Шәмәрдән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2009 елның 28 декабрендә кабул ителгән «Шәмәрдән авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында» гы 18 нче номерлы карары белән расланган Шәмәрдән авыл җирлеге Советы Регламентына үзгәрешләр кертергә:

1.1. Регламентның 6 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

"34.1 Статья.

1. Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук законнар, Шәмәрдән авыл җирлеге Уставы белән вәкаләтле башка вазыйфаи затлар Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Шәмәрдән авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Башкарма комитет хезмәткәрләре Совет тарафыннан алар карамагына караган мәсьәләләрне караганда ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр бу тәкъдим депутатларның гомуми санынннан абсолют күпчелеге тарафыннан кабул ителсә, Совет утырышында җирле үзидарәнең вазыйфаи

затлары катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Таләп, кимендә өч көннән дә соңга калмыйча, утырышка кадәр, Совет рәисе тарафыннан, утырышны уздыру вакытын, урынын күрсәтеп, чакырылган вазыйфаи затның белешмәләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаи затның Совет утырышына чакыртыла торган мәсьәләсенә җиткерелә.

5. Совет рәисе утырыш ачылыр алдыннан утырышта катнашучы Совет депутатлары булмаган затлар турында хәбәр итә.

6. Утырышта катнашучылар һәм чакырылган затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел (чыгыш ясарга, гариза ясарга, хуплау яисә канәгатьсезлек белдерергә).

7. Совет карары буенча чакырылган затларга әлеге «регламент»кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shemordan һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

3.Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гәрәев